# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы  Ромодан авыл җирлеге составына керүче Ромодан авылы

№ 2

11 ноябрь 2019 ел.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авылҗирлеге составына керүче Ромодан торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда  Ромодан авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы  студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге  чараларга юнәлдерергә:

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- урам утларын карап тоту;
- балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру ( Беренче Ферма п.)

3.Әлеге карарны Ромодан авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ромодан авыл җирлеге башлыгы И.А. Чекалина

СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ